**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «08» сентябреннән № 183

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Программасын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендә 2025 елга җирле бюджетта «295,0» санын «300,556» санына алмаштырырга;

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендә 2025 елга республика бюджетын түбәндәге эчтәлекле «555,6 мең сум

(«Сосновка» чаңгы базасын җиһазландыру»)) сүзләрен өстәргә;

«Программаны финанс белән тәэмин итү» турындагы 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

«

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Сосновка» чаңгы базасын җиһазландыру һәм карап тоту (республика бюджеты) | - | - | - | - | 555,6 | 555,6 |
| 3 | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Сосновка» чаңгы базасын җиһазландыру һәм карап тоту (җирле бюджет) | - | - | - | - | 5,556 | 5,556 |

».

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 03 июнендәге 132 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Фасахов